гә» калган Болгар мәйданнары, «селтегә әверелдерелгән ил күгенең яңгырлары» турында язганда да без шагыйрьнең үз халкының бөеклеге белән горурлануын, аның асыл сыйфатлары белән соклануын сизәбез:

Сыйфатың шундый, күрәсең,  
Җитсә дә меңгә яшең,  
Ак кынам, пагым, сафым! — дип  
Аклыны үзсенәсең...

Күренекле мәгърифәтче Зыя Камали, атаклы артист Мохтар Мутин турында язганда да шагыйрь күңелендә, бераз әрнү хисе белән кушылып, шундый ук горурлык хисе балкый. Шагыйрь иленең, халкының киләчәге турында уйлана, офыкларның еракларын күзәтә, «безгә анда — ерак гасырларда — укучылар очрарлар микән?» дип борчылып, киләчәккә сорау бирә. Һәм «һаман саны арткан укучылар авазы аша» киләчәк аңа түбәндәге җавабын бирә:

Ут та алмый, туп та ватмый торган  
Байлыгымны бәгыремә салып,  
Мин түгелме, тулы гасырларның  
Тугызлабын сау кичкән халык,  
Җырларымны җаныма сарып?!

Димәк, шагыйрь киләчәккә ышана, өметләнеп карый. Шуңа охшашлы фикерләрен ул Дәрдмәндкә ияреп язган «Җилкәнен киерә кораб» исемле шигырендә дә, «Еракларга алып киттеләр» дип исемләнгән парчаларында да (чынлыкта исә алар ниндидер зур поэманың өзекләрен хәтерләтә) һәм башка әсәрләрендә дә үткәрә.

Хәсән Туфан — чын мәгънәсендә шигъри җанлы кеше. Ул шигырьләрендә генә түгел, тормышында да чәчәкләргә гашыйк. Аның Аккош күлендәге дачасы җәй көннәрендә шау чәчәккә күмелеп утыра.

...Х. Туфан әле бүген дә поэзиябезне әйдәп баручылар сафында. Ул бөтен күңеле белән алга омтылып яши. Аның 1941 елда язган сүзләре бүгенге иҗатына да бик тә килешеп тора:

Үтик әйдә  
Калган гомерне дә,  
Үтик бары — алга барышлый,  
Артта түгел: бушлай, бушка түгел;  
Ә крепостьлар яулап алышлый  
Һәм халыкка юллар салышлый!



Чыганак: Мостафин, Р. Җаваплылык тойгысы / Р. Мостафин.- Казан: Татар. кит. нәшр.,1979.- 200 б.

## ШИГЪРИЯТ ЧИШМӘСЕ

*(Сибгат Хәким)*

Туган авылым Баулы янында өсте яшь юкә һәм имәннәр, бөдрә вак каеннар белән капланган сөзәк кенә бер тау бар. Аның итәгеннән салкын сулы чишмә агып чыга. Көчле, тигез агым белән төптән кузгатылган ком бөртекләренең өзлексез бөтерелүен карап, мин озак-озак шул чишмә янында утырырга яратам; үз юлында яткан ташларга бәрелеп, аның көмештәй чылтыравын тынлыйм, дымлы туфракта үскән үләннәрнең исен рәхәтләнеп сулыйм.

Юл өстеннән читтәрәк агып яткан ялгыз бер чишмә...

Ләкин ерак диңгезгә һәм океаннарга коя торган мул сулы, куәтле елгалар да әнә шундый төптән, җирнең үзәгеннән кайнап чыккан чишмәләрдән башлана бит.

Өлкән шагыйребез Сибгат Хәким иҗатын да мин әнә шундый — җирнең, тормышның төбеннән кайнап чыккан көмештәй саф сулы шигърият чишмәсе итеп күз алдына китерәм.

* * *

Тумыштан әкият, җыр-шигырь чыгару сәләте булган кешеләр турында тау халыклары: «ул авызына көмеш кашык кабып туган», диләр. Күренекле шагыйребез Сибгат Хәким дә — шундый бәхетле кешеләрнең берсе. Аның «көмеш кашыгы» — бабаларыбызның меңеллык тәҗрибәсен һәм акыл көчен сеңдергән шигъри бизәкләргә гаҗәеп бай, тылсымлы халык теле.

Сибгат Хәким Казан артында туып үскән, Казан арты исә әлек-электән җырлы як булуы, зур шагыйрь-

ләре, атаклы галимнәре белән дан тоткан. Бу якта безнең милли горурлыгыбыз — татар халык шагыйре Габдулла Тукай туган. Үткәннең мәшһүр галимнәре һәм акыл ияләре Курсави, Шиһап Мәрҗани, татар әдәбиятының классик драматургы Галиәсгар Камал Казан артыннан чыкканнар. Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, М. Мәһдиев кебек танылган язучыларыбыз да шунда туып үсәләр.

Бу очраклы хәл түгел. Төрле тарихи сәбәпләр аркасында, халыкның әдәби теле үзенең беренчел сафлыгы, искиткеч байлыгы белән нәкъ шул якларда тулырак сакланган. Әдәби телебезгә нигез итеп тә Казан арты сөйләме алынган. Биредә туган җырларны бөтен республика җырлый, Казан арты әкиятләрен бөтен халык белә. Булачак шагыйрьнең балачагы әнә шул төбәктә — җырга-моңга бай якта, атап әйткәндә, Арча районының Күлле-Киме авылында уза.

Казан арты... Көлсу туфраклы, соры комлы, рәшә уйнаган офык читендә кучкылланып утырган чыршылар, кояш нуры белән өретелгән ап-ак каеннар үсә торган төбәк. Ул элек-электән үзенең алтын куллы осталары, эш сөючән гади кешеләре белән дан тоткан. Сибгат Хәким шигырьләрендә бу як нәкъ әнә шулай сурәтләнә дә. Ул — туган ягын ихлас күңелдән сөя торган кеше. Аның иҗатында туган як темасы халык язмышы белән тыгыз үрелгән. Чөнки ул үзе дә гади халык арасыннан чыккан.

Шагыйрьнең нәсел шәҗәрәсе Мәмкә атлы карттан башлана икән. Гаделлеге өчен, авыл халкы аны җир бүлүче итеп сайлый. Ул, озын һәм авыр чылбыр сөйрәп, иген басулары буйлап җир бүлеп йөри. Аның артыннан тигез, туры эз сызылып кала. Монда күп нәрсә җир бүлүченең тәҗрибәсенә, бигрәк тә аның гаделлеге һәм риясызлыгына бәйләнгән.

«Безнең буын — озын чылбыр ул» шигырендә шагыйрь Мәмкә бабасын болай дип искә ала:

Мәмкә торган буын башында,
Бер сүз белән әйтсәк: межачы...
Авыл белән авыл арасын
Ярып узган дөнья нужасы.
...Хәзер дә бар Мәмкә елгасы,
Бар да дөрес, бар да чын монда.
Җир бүлгәндә шушы елгада
Елаган ул ятып чылбырга.



Мәмкә картның күркәм сыйфатлары алар нәселенең башка буын вәкилләренә дә күчә. Һәм шагыйрь үзен шул нәселнең өзелмәс бер буыны итеп саный.

Буын-буын озын чылбырны —
Һич өзелмәс моңлы шул җырны
Ничә еллар инде, ни заман
Үзем сөйрим хәзер межадан.

Сибгатнең ата-бабалары, урман әрчеп, чәчүлек җир хәзерләгәннәр, күпме көч куеп, маңгай тире агызып тапкан шул җирдә арыш, карабодай үстергәннәр. Аның белән генә тамак туйдыра алмагач, күрше авылларга балта эшенә йөргәннәр. Балта остасы буларак, әтисенең даны бөтен тирә-якка таралган, ә үзенә ул юньлебашлы бер өй дә салып керә алмаган. Мохтаҗлык башка кешегә эшләргә мәҗбүр иткән.

«Югалган эзләр» шигырен укыганда безнең күз алдына шагыйрьнең әтисе — ак алъяпкыч япкан, билбавына үткен балтасын кыстырган киң җилкәле крестьян килеп баса. Без аның мускуллары кабарып, кан тамырлары бүртеп торган таза беләкләрен, сагыз исе сеңгән сөялле кулларын күргәндәй булабыз.

Шагыйрьнең әнисе Газзә апа тугыз бала тәрбияләп үстерә. Ул киң күңелле, булганны бәрәкәтле итеп тота белә торган, тормыш һәм кешеләр хакында айнык фикер йөртә белгән хатын була. Туган авылына кайткач, шагыйрь әнисе белән озак-озаклап сөйләшеп утырырга ярата, үзен борчыган бик күп сорауларга аннан акыллы киңәшләр ала.

Сибгат Хәким әсәрләрендә без Ана образын еш очратабыз. Авыр югалту, көенечле хисләр белән сугарылган «Васыятьләр» поэмасы шагыйрьнең әнисенә багышланган. Ана образы әдип аңында туган як, Ватан һәм халык образы белән кушыла. Үлем түшәгендә яткан әнисенең соңгы васыяте аның колак төбендә яңгырый:

...кайткала, ташлама бу йортны,
Бабаңнар рухы бу нигездә...

1921 елгы ачлык вакытында әтисе белән абыйсы, эш эзләп, Донбасс якларына чыгып китәләр. Һәм шул китүдән берсе дә әйләнеп кайтмый: тиф белән авырып,

юлда үлеп калалар. Ун яшьлек Сибгатнең күз алдында, ачлыктан шешенеп, бабасы белән сеңлесе Разия үлә. Ул үзе дә көч-хәл белән генә исән кала...

* * *

Аерым хуҗалык булып яшәүче крестьян тормышының авырлыгын Сибгат кечкенәдән үз иңендә татый. Үзләренә тиешле уч төбе хәтле җирне эшкәртү өчен дә аларга күпме көч, күпме тир түгәргә туры килә! Ләкин шагыйрь күңеленә ул еллар үзенең авырлыгы, мохтаҗлыгы һәм ачлыгы белән генә түгел, шау-шулы бәйрәмнәре, якты истәлекләре белән дә кереп калган. «Васыятьләр» поэмасында шундый бәйрәмнәрнең берсе тасвирлана:

Барсы да халыкта, фәкать шул
Халыкта, мин кабат аңладым;
Шул Казан артының күңелдә
Бастырдым мин кала-тауларын.

Җыены, бәйрәме... Басуда
Рәхәт бер җылысы ашлыкның.
Ат, арба, канатлы тарантас
Буеннан-буена Ашытның.

Мондый бәйрәмнәр, гадәттә, Болгар дәүләте чорыннан сакланып калган хәрабәләр һәм кабер ташларына бай Кала тау итәгендә үткәрелгән. Бу — изге урын саналган. Тау астыннан агып чыккан чишмәгә уннарча, йөзләрчә чакрымнан гыйбадәт кылырга карчыклар килә торган булган. Тау башындагы Болгар хәрабәләре турында исә бик күп легендалар, бәет һәм дастаннар сөйләнгән. Шул рәвешчә, шагыйрь бала чагыннан ук «чал тарихның үзе белән» йөзгә-йөз очрашкан.

«Ә халыкның үз җырлары! Аның характерына хас ниндидер уйчан, тыйнак моң,— дип яза соңрак шагыйрь.— Әйтерсең лә алар халыкның үз язмышыннан саркылып чыкканнар. Йөрәгеңә бер кердеме, тиз генә китмәс, иң түренә, эчкәрегә үк кереп утырыр да мәңгегә калыр... Әле малай чакта ук, берәр авылда җыен буласын ишеттемме, тизрәк шунда чаба идем. Ризыктан күп әләкми, аның каруы туйганчы җыр тыңлыйм. Һәм хәзер дә, илленең өске ягына чыкканнан соң да, шул ук «авыру» белән авырыйм... Мин бүген дә бер генә



сабан туен да калдырмыйм. Һаман да шул, халыкның үзенә бертөрле, үзенчәлекле тормышы тарта».

Малай чагында С. Хәкимнең үзе кебек үк җыр яраткан Исмәгыйль исемле дусты булган. Алар еш кына үзара ярыша торган булганнар. Кем күбрәк җыр белсә, шул җиңүче булып чыккан. Ул ярышларда еш кына Сибгат җиңә торган булган...

Кечкенәдән халык җырларын, Тукай моңнарын тыңлап-ишетеп үскән Сибгат бик иртә кулына каләм ала, күңелендә туган уй-хисләрен «рифмалашкан юлларга» салырга тырышып карый. Күрәсең, аның өйрәнчек шигырьләрендә үк нәрсәдер булган инде. Юкса, укытучысы Фәрит Гасыймов малайның күңелен күтәрерлек мактау сүзләре әйтмәс иде...

Бишенче класстан алып Сибгат иҗат түгәрәгенә йөри, стена газетасында һәм мәктәптә чыгып килгән кулъязма журналда шигырьләрен «бастыра» башлый. Бервакыт Күлле-Киме авылына Гадел Кутуйның сеңлесе Һава Кутуева килә. Кичәдә Сибгатнең шигырьләрен тыңлагач, ул аны үз янына чакырып ала да:

— Сездә әдәби эшкә сәләт бар: укуыгызны дәвам иттерергә кирәк,— ди.

Сибгаткә ул Казанга килергә куша, укырга керергә дә булышырмын, ди. Адресын калдыра. 1930 елның җәендә унтугыз яшьлек крестьян егете, гомерендә беренче мәртәбә туган җиреннән аерылып, ерактагы чит-ят шәһәргә чыгып китә. Бирегә килгәч, Һава Кутуеваның ярдәме белән, ул башта татар рабфагына укырга керә, соңыннан педагогия институтына күчә.

* * *

Үзара шаярып сөйләшкәндә, каләмдәш дуслары: «Сибгат татар поэзиясенә «Пар ат»та килеп керде»,— диләр. Уйлап карасаң, бу сүзләрдә шактый зур дөреслек бар. 1939 елда басылган «Пар ат» поэмасында С. Хәким шагыйрь буларак үз тавышын таба. Аның иҗатының төп үзенчәлекләре дә, эчкерсез лиризм белән сугарылган көмеш кебек саф тавышы да шушы әсәрдә башлап ачыла.

Аның шигъри авазы нәфислеге, йомшаклыгы белән аерылып тора. Поэмага нюанслар байлыгы, хис-кичерешләрнең иң нечкә төсмерләрен сиземли алу хас, ан-

дагы хис-тойгы һәм вакыйгаларның агышы ук ниндидер салмак, үзенә бертөрле ритмга салынган. Өрфия пәрдә белән өретелгәндәй беленер-беленмәс моң-сагыш та, халык шагыйре Тукайның вакытсыз үлеме өчен әрнүачыну да, артык сизелеп, күзгә ташланып тормаслык ниндидер тантана хисләре дә бар анда.

Җик атларны, кучер, кузгалабыз...
Күзлим кабат тирә-ягымны.
Кешеләрең якын синең, Кырлай,
Бөтен нәрсәң җанга ягымлы.

Поэмадан Габдулла Тукай поэзиясенә хас үзгә бер аһәң сизелеп тора. Шигъри тонның уйчанлыгы, яктылык нуры сибелгән моң, эчке бер җылылык, туган җиргә, аның эшчән кешеләренә булган чиксез мәхәббәт С. Хәкимне Тукайга якынайта.

«Пар ат» поэмасында эзлекле бер сюжет линиясе юк диярлек. Әсәр туган як табигате турында лирик кичерешләр симфониясе буларак яңгырый. Шагыйрь тормыш турында уйлана, үткәннәрне хәтергә төшерә, киләчәкне күзалларга тырыша һәм әледән-әле Тукай образына мөрәҗәгать итә.

Дөрес, поэма кимчелекләрдән азат түгел. Урыныурыны белән аңа хис тирәнлеге, чынбарлыкны фәлсәфи яктан аңлау һәм аңлата белү җитенкерәми. Автор аерым урыннарда туган як табигатенең тышкы сыйфатларын санау белән мавыга:

Якын миңа: әвен, кибәннәрең,
Болыннарың, иркен кырларың,
Томан төшкән яшел үзәннәрең
Һәм зәңгәрсу торган урманың...

Әмма югарыда әйтелгән бу кимчелекләр генә поэманың көчле, матур якларын күмеп калдыра алмый. Шагыйрь үзенә якын кадерле балачак, туган як турында яза. Әсәрдә укучының игътибарын җәлеп иткән һәм бүген дә үзенә тартып торган бер сыйфат бар — аңа хис-тойгы табигыйлеге, җылы, шигъри лиризм хас.

* * *

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк татар язучыларының күбесе яу кырына китә. Сугыш беркемне дә аяп тормый. Татар әдәбияты бик күп талантлы



язучыларын югалта. Аларның байтагы — Сибгат Хәкимнең якын дуслары, замандашлары һәм каләмдәшләре. Фатих Кәрим сүзләре белән әйткәндә, аларның барысы да газиз Ватанга соңгы сулышларынача тугрылыклы булып калган патриотлар:

Кайту да юк ләкин, кавышу да
Дошманнарны әгәр җиңмәсәк.
Данлы җиңү байраклары белән
Илнең кайгы яшен сөртмәсәк.

Фронтовик шагыйрьләрнең көчле поэтик авазына Сибгат Хәкимнең дә үзенчәлекле фронт лирикасы килеп кушыла. Дөрес, бу елларда шагыйрь әллә ни күп язмый. Аның бу чорда иҗат иткән шигырьләре сугыш еллары татар поэзиясендә дә, шагыйрьнең үз иҗатында да зур урын тотмый. Аларда әле эчке яну, хисләр киеренкелеге җитенкерәми.

Моны ничек аңлатырга соң?

Минемчә, барыннан да элек, фронт тормышына хас кырыс шартлар белән. Шагыйрь үз иңендә сугышның барлык авырлыкларын күтәрә, солдатлар белән бергә салкын окопларда туңа, тоташ ут астында яши, алар белән бергә һөҗүмгә бара, сугышчылар белән соңгы сыныгын, соңгы тәмәкесен бүлешә. Бу елларда взвод командиры Сибгат Хәким өчен үзенә тапшырылган сугышчан бурычны үтәүдән дә зуррак эш булмый. Шигырьләр исә һөҗүм тынып торган кыска вакытлы ял араларында, привалларда, кан һәм үлемне онытып торырга тырышкан минутларда языла.

Сугыш бетеп, берничә ел вакыт узгач, шагыйрь болай дип яза:

«...Сугышларда мин — үз гомеремдә беренче тапкыр дисәм дә ялгыш булмас,— кешеләрне таныдым, совет кешеләренең көчле, бөек рухына сокландым. Хәзер менә шактый еллар узганнан соң артка борылып карыйсың да сине ул вакытта көрәшкә илһамландырган көчнең, ышанычның каян килгәнен яхшырак төшенәсең. Сугышта сине чиксез куандырган нәрсә — үз-үзеңне дошманыңнан күп өстен, күп көчле итеп хис итү. Син аннан техникаң белән генә түгел, иң изге теләкләрне, идеяләрне тормышка ашыручы совет кешесе буларак өстен, син үз эшеңнең хаклыгы, гуманлы булуы белән аннан буй җитмәс дәрәҗәдә югары торасың...»

Шагыйрь сугыш турындагы иң күренекле әсәре «Дуга» поэмасын һәм полкташ дусларына багышланган шигъри циклларын сугыштан соң күп еллар үткәч язган икән, бу, күрәсең, әнә шул хәл белән аңлатыладыр.

* * *

Шунысы кызык, сугыш елларында әллә ни күп язмаса да, С. Хәким шул чакта ук иң популяр шагыйрьләрнең берсенә әйләнә. Моның кызыклы гына тарихы бар. Хәзер шул хакта берничә сүз.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан, хәтерем ялгышмаса — 1938 елда бугай, ул чагында әле яшь язучылар рәтендә йөргән Сибгат Хәким «Юксыну» исемле мәхәббәт шигыре яза.

Шигырьнең эчтәлеге артык катлаулы түгел. Лирик герой бик тә юксынып һәм ямансулап сөйгәнен көтә. Җылы якларга киткән кошлар кире әйләнеп кайта, аның сөйгәне генә никтер һаман күренми. Герой кайчандыр сөйгәне укыган мәктәп яннарыннан уза: менә-менә иптәшләре белән шау-гөр килеп ул килеп чыгар сыман...

Бер ул гына түгел, хәтта бакчадагы шомырт агачлары да «аны» сагына, «аны» көтәләр. Тик яфраклар коела, чәчәкләр шиңә, лирик геройның сөйгәне генә һаман күренми.

«Юксыну» беренче тапкыр шагыйрьнең 1938 елда чыккан җыентыгында басыла. Ләкин ул чакта аңа артык игътибар итүче булмый. Сугыш башлана... Авыр, дәһшәтле 1942 ел җитә.

Немец илбасарлары Иделгә якынлашып килә... Ил язмышы хәл ителергә тиешле хәвефле көннәр башлана. Шундый көннәрнең берсендә, С. Хәкимнең кайчандыр бүләк иткән җыентыгын караштырып утырганда, композитор Шакир Мәҗитов «Юксыну» исемле әлеге шигырьгә юлыга:

. . . . . . . . . . . . . . .
Син киләсе юлдан күзем алмый
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән...

Композитор дулкынланып, бер төн эчендә яңа көй яза. Таң атып, яктыруга, фикерен белергә теләп, Заһит



Хәбибуллин янына чаба. Ул дусты Ш. Мәҗитовны уңыш белән котлый.

Берничә айдан «Юксыну» бөтен республикага тарала. Ул сугышка киткән ярыннан хәбәр көтеп яшәгән кызларның үз җырлары кебек яңгырый. Авыл клубларындагы бер генә концерт, бер генә кичә дә бу җырсыз узмый. Халык С. Хәким шигырендәге кайбер сүзләрне үзенчә үзгәртә, аны тагын да камилләштерә.

Бу вакытта автор үзе фронтта була. Кайчандыр язган бер шигыре шулкадәр популяр булып китәр дип уена да китерми.

1946 елда С. Хәким Казанга кайта. Беркөнне аңа урамда Зифа Басыйрова очрый. Исәнлек-саулык, хәләхвәл сорашалар, шуннан артистка «Юксыну»ның халык тарафыннан гаять җылы кабул ителүе, бик популяр булуы турында сөйли башлый.

— Беләсезме, Зифа ханым,— ди С. Хәким, уңайсызланып,— минем ул җырны ишеткәнем дә юк бит әле.

— Булмас ла! — дип гаҗәпләнә җырчы.— Алайса, Татарстанда ул җырны ишетмәгән бердәнбер кеше сез буласыздыр...

* * *

Сөйгәннәрен, гаиләләрен сагынган солдатларның яу кырыннан азат җирдәге тыныч хезмәткә кайтуы сугыштан соңгы совет поэзиясендәге үзәк темаларның берсенә әйләнә. Ул мотивлар Сибгат Хәким поэзиясендә дә көчле яңгыраш ала һәм иң элек аның пейзаж лирикасында чагыла. «Туган як», «Туган җир», «Таң атканда», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» кебек шигырьләренең исемнәре үк шул хакта сөйли. Бу шигырьләрдә туган-үскән җиреннән аерылып торган лирик геройның Ватанга булган мәхәббәте яңа көч белән гәүдәләнә.

Әлеге шигырьләрне укыганда, Рәсүл Гамзатовның: «Туган ягыңны ярату тойгысын ачлык белән генә чагыштырырга мөмкин. Аны җиңү мөмкин түгел», дигән зирәк сүзләре искә төшә. Шагыйрь, чыннан да, туган җирен өзелеп сагына. Ләкин аның хисләрендә күзгә бәрелеп торырдай шапырыну, аһ орулар юк диярлек. Ул хисләр төптә, бик тирәндә ята.

Сибгат Хәкимнең бу шигырьләрен сугышка кадәр үк шул темага язылган башка шигырьләре белән чагыштырып карау да кызыклы.

Сибгат Хәкимнең баштагы шигырьләрендә туган як темасы еш кына традицион рухта чишелә иде. Аларда я халык җырлары интонациясе, я Тукай поэзиясе аша таныш образлар күзгә ташланып тора. Сугыштан соңгы шигырьләрендә дә автор традицияләрне дәвам иттерүче буларак эш итә, аның лирикасы татар поэзиясенең күп гасырлык тарихына нигезләнә. Шул ук вакытта аның кабатланмас индивидуаль йөзе көннән-көн ачыграк беленә бара.

Әлбәттә, бу әле аның ахырынача өлгереп җитүе түгел, бары тик шуңа бару юлы гына. Сугыштан соңгы тормышның эченә кереп, аның кичектергесез проблемаларына мөрәҗәгать иткәнче шагыйрьгә күпмедер вакыт кирәк була.

Ул берничә ел буе «Бакчачылар» исемле зур күләмле лиро-эпик поэма өстендә эшли. Сугыштан соң ук языла башланган бу әсәр бары тик 1952 елда гына тәмамланып басылып чыга. Шагыйрь 1957 елда әлеге поэмага янә әйләнеп кайта һәм аңа күп кенә төзәтмәләр, өстәмәләр кертә. Поэманың төрле вариантларын чагыштырып караганда шагыйрьнең профессиональ осталыгы үсә баруын күрәсең.

Сибгат Хәким — асылда лирик шагыйрь. Ул чынбарлыктагы вакыйга һәм күренешләрне йөрәге аша үткәрә. Танылган тәрҗемәче С. Липкин бик дөрес әйткәнчә, без аның шигырьләрендә коры фактларга гына түгел, аннан да мөһимрәк нәрсәгә — хискә ышанабыз. Башка тәнкыйтьчеләр һәм рецензентлар да С. Хәким поэзиясенең кичерешләргә бай булуына, кеше күңеленең иң нечкә хисләрен ача алуына басым ясап әйтәләр.

* * *

Бервакыт Татарстан радиосы Сибгат Хәкимнән халык арасында киң таралган бер көйгә текст язып бирүен үтенеп мөрәҗәгать итә.

«Озак уйландым,— ди шагыйрь,— шушы гади генә, эчкерсез мелодиягә ниндирәк сүзләр табарга соң? Акрынлап, кат-кат тыңлый торгач, көйдә мин чылтырап аккан чишмә тавышлары ишеткәндәй булдым. Күз алдында авыл күренешләре, яшьләрнең чишмә буенда очрашулары җанланды, башымда үзеннән-үзе җырның сюжеты туды».



«Фазыл чишмәсе»ндә чиләк-көянтәләрен асып, «чылтырап аккан чишмәгә» суга дип килгән бер кыз турында сүз бара. Автор бик гади, шул ук вакытта хәтердә калырлык итеп, яшьләрнең очрашып-кавышуларын сурәтли. Егет белән кыз бер-берсенә купшы, матур сүзләр әйтешми. Аларның, кавышып, үзара аңлашулары кинаяле сүзләргә, күз карашы һәм ишарәләргә генә корылган:

Кызарып янган шәфәкътән
Күзләрем алалмадым;
Тибрәнде телем, әйтергә
Сүзләрем табалмадым.

Бу юлларда тыйнак, оялчан һәм саф күңелле татар кызының самими холкы, тулы характеры ачыла. Күрәсез, ул сөйгәненең йөзенә күтәрелеп карарга да кыймый, күзләрен каядыр читкә, шәфәкъ ягына төбәгән. «Кызарып янган шәфәкъ»ка монда икенче, өстәмә мәгънә дә салынган әле. Алдагы строфада болай ди бит шагыйрь:

Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.

Ирексездән елмаю уята бу сүзләр. «Тиз генә өйгә кайтырмын» дип суга киткән кыз кояш баеп, караңгы төшкәнче егете янында басып торган бит. Кызның каушый-курка беренче мәртәбә сөйгәне белән аңлашканнан соң әйткән сүзләре дә бик табигый, ышандырырлык янгырый:

Вәгъдәм бар сиңа, белмәсен
Тик күрше-күлән генә.

«Фазыл чишмәсе»ндә җиңелчә юмор һәм шаянлык, татар халкына хас тыйнаклык һәм күңел сафлыгы — барысы бергә кушылган. Һәм җырдагы сукмак та әйтерсең чылтырап аккан чишмәгә генә түгел, халыкның күңел түренә үк илтә. «Юксыну» кебек үк, «Фазыл чишмәсе» дә халкыбызның яраткан җырына әйләнә.

Укучылар белән очрашканда С. Хәкимне еш кына «Фазыл чишмәсе кай төштә, нинди авыл янында ул?» дип аптырата торган булганнар. Һәм авторга аның шагыйрь фантазиясе белән генә уйлап чыгарылган чишмә булуын аңлатып бирүдән башка юл калмаган...

Бер елның җәендә С. Хәким, гадәттәгечә, туган авылы Күлле-Кимегә кайта. Авылдашлары аңардан

хәл-әхвәл, сәламәтлеге, нинди әсәрләр язуы турында сорашалар, шәһәр яңалыкларын сөйләтәләр. Ахырдан берсе шунда әйтеп куя:

— Фазыл чишмәсен күрергә телисезме? — ди.

— Нинди чишмә ул? — дип аптырый С. Хәким... Соңыннан барысы да ачыклана. Авыл янында салкын, чиста сулы яңа чишмә чыга башлаган. Һәм авыл яшьләре аңа «Фазыл чишмәсе» дип исем кушканнар икән.

* * *

Шуны искәртеп китәргә кирәк: Сибгат Хәким әзер көйгә җыр текстларын бик сирәк яза. Татар композиторлары, гадәттә, аның лирик шигырьләрен көйгә салалар. Әмма көйгә салынгач, аларга канатлар үсеп чыккандай була, һәм ул әсәрләр бөтенләй көтелмәгән үз тормышлары белән яши башлыйлар. Аның сүзләренә язылган җырларда халык күңеленең иң матур сыйфатлары — чыдамлык, Ватанга мәхәббәт, кешелек горурлыгы кебек олы хисләр гәүдәләнә. Дөрес, ул җырларда, әйтик, рус халык җырларындагы киңлек һәм иркенлек юк диярлек. Алар ифрат тыйнак, басынкы. Ләкин бу тыйнаклык, оялчанлык бай хисләр ташкыны белән үрелеп бара. С. Хәким сүзләренә язылган җырлар сугыш елларында халыкның җиңүгә булган ышанычын арттырсалар, тыныч чорда алар кешедә мәхәббәт һәм дуслык кебек гүзәл хисләр тәрбиялиләр. Шагыйрь бай сурәтләү чараларына халыктан өйрәнә, татар халык җырларына хас параллелизмнардан оста файдалана, бу традицияләрне үстереп, аларны яңа бизәкләргә баета. Аның сүзләренә иҗат ителгән иң әйбәт җырлар күптән инде музыкаль сәнгатебезнең классик фондына керде. Алар арасында «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Таң атканда», «Казакъ дустыма», «Тынычлык солдатлары», «Якты таң», «Җитенче кыз җыры», «Чын йөрәктән», «Кем уйлаган», «Барысы да йөрәктә» кебек байтак җырлар бар.

Бездә җыр күп языла. Ләкин халык ул җырларның бик азын гына үзенеке итеп ала. Җырның халыкка таралуы өчен сүзләренең матур, ятышлы булуы гына җитми, ул халык күңелендәге хис-тойгылар белән сугарылган булырга тиеш. Сибгат Хәким үзенең иң уңышлы җырларында әнә шуңа ирешә дә инде.



Бервакыт мин Сибгат Хәким сүзләренә байтак җыр язган композитор Рөстәм Яхиннан шагыйрь шигырьләре аны нәрсәсе белән җәлеп итүләре турында сорадым.

«Аның шигырьләрендә лиризм шулкадәр көчле, алар үзләреннән-үзләре көйгә салуны сорап торалар. Иң мөһиме, ул шигырьләр әзер трафаретка корылмаган. Аларга һәрбер очракта яңача якын килергә, яңа бизәкләр эзләргә кирәк»,— диде композитор.

Әйе, Сибгат Хәким — иҗатта схема һәм шаблонга, әзер алымнарга каршы кеше. Аның һәр шигыре — үз алдына мөстәкыйль яши торган һәм ахырынача эшләнеп беткән сәнгать әсәре. Шул ук вакытта шагыйрь җыр жанрының үз кануннары барлыгын да яхшы аңлый. Кайчандыр ул җырның драматизмга ия булырга тиешлеге турында махсус мәкалә язып чыккан иде. Җырда үзенә күрә сюжет тәшкил итәрлек эчке бер психологик хәрәкәт булырга тиеш. Бу, әлбәттә, һәр җырның нигезендә берәр вакыйга ятарга тиеш дигән сүз түгел. Әмма анда аерым юлларны, строфаларны бер-берсенә беркетә, бәйли торган хис булуы мәҗбүри. Шулай булмаганда, җырда артык сүзгә урын калуын көт тә тор.

Шагыйрьнең «Юксыну» шигыре һәм шул исемдәге җыр тексты — нигездә икесе ике әсәр. Беренчесендә лирик геройның яшьлек дустына әйтелмәгән мәхәббәте турында сүз барса, икенчесендә узган сугыш белән бәйле уй һәм тойгылар, аерылу һәм югалту хисләре тасвирлана. Җыр тексты шигырьгә караганда өч тапкыр кыскарак, эчтәлеге, фикере исә тирәнрәк һәм киңрәк. Ә менә «Фазыл чишмәсе» башта өч кенә куплеттан торган. Җыр мехчылар клубында беренче тапкыр башкарылганда артистлар да, тыңлаучылар да, автор үзе дә аның төгәлләнеп җитмәгәнлеген сизәләр. Хикмәт монда җырның кыска булуында гына түгел, ә сюжетның психологик яктан тәмам йомгакланып җитмәвендә. Ахырдан шагыйрь җыр текстына тагын ике строфа өсти. Шулай итеп, аның бүгенге көндә җырлана торган варианты барлыкка килә.

* * *

1948 елның җәендә С. Хәким көньякка ял итәргә бара. Поезд кайчандыр ул сугышып узган җирләр — Орел, Курск, Белгород шәһәрләре аша үтә. Таныш,

якын җирләр. Җылы җил кырлардан өлгергән арыш исе алып килә. Әнә юлдан, тузан туздырып, колхоз терлекләре кайта. Һәр йорт каршында диярлек сары бүрәнәләрдән буралган яңа буралар калкып чыккан, яңа ярган такта, кирпеч өемнәре тезелгән. Тимер юл буендагы яртылаш җимерек окоп-траншеяларны үлән каплап киткән.

Юл кырыенда Прохоровка авылы күренгәч, шагыйрь йөрәге тагын да көчлерәк тибәргә тотына. Курск дугасында коточкыч канлы сугышлар барганда, аның взводы шушы тирәләрдә оборонада тора. Биредә аның иң якын дуслары үлеп кала, ул үзе авыр контузия ала. Шушында ул Коммунистлар партиясенә керә.

Сугышып узган җирләре аша көньякка барганда туган уй-хисләрен С. Хәким үзе болай дип аңлата: «Күзләрем тәрәзәдә. Юл буендагы куаклар артыннан бергә хезмәт иткән дусларым-солдатларым каршыма килеп чыгар кебек тоелды. Аларның төсләрен, буй-сыннарын, үзләрен тотышларын күз алдына китердем, аларны сагындым. Бөтен үткәнем кабат терелде.

Вагон тәрәзәсеннән кергән таныш җил күңелнең әллә кай төшенә кагылды, күңелем тулды, карадым, аерыла алмый бөтен нәрсәгә йотлыгып карадым. Менә шунда минем әрни-әрни язасым килде. Күңелемдә минем бар да өлгергән, бар да әзер, күңелем ул хисләрне кемгәдер әйтергә, ярсый-ярсый сөйләргә тели иде. Безнең халыкның үткән сугышта күрсәткән батырлыгы белән горурлануымны сөйлисем килде».

Көньяктан кайту белән, С. Хәким дәртләнеп эшкә керешә. Зур көч сорый торган әсәрләр язарга уйласа, ул туган авылы Күлле-Кимегә кайта торган була. Бу юлы да шулай эшли. Поэма сары идәнле бәләкәй генә авыл мунчасында языла һәм, әйтергә кирәк, бик тиз языла. Күп тә үтми, «Курск дугасы» исемле кечкенә генә бу поэма «Совет әдәбияты» журналында басылып та чыга. Поэманы киң катлау укучылар да, шагыйрьнең дуслары да җылы каршылый. Әсәр тирән лиризмы, гадилеге һәм кайнар хисләре белән үзенә тарта:

Ачып куйдым вагон тәрәзәсен,
Тәмле исләр керсен арыштан.
Үзебез азат иткән җирдән узам,
Кай арада биш ел авышкан.



Поэманың буеннан-буена совет солдатларының каны юкка гына коелмады дигән идея үткәрелә. Алар, үзләренең гомерләрен биреп, илебезнең бүгенге шатлыклы, тыныч көнен саклап калдылар. Бу яктан поэма Гадел Кутуйның окоптан язган «Рус шәһәрен ярсып яклаганда, күзләремә Казан күренә!» — дигән шигъри юллары белән аваздаш.

Гадел Кутуй кебек үк, С. Хәким дә ерактагы рус авылы Прохоровка янында үзенең Күлле-Кимесен саклый:

Прохоровка туган авылым түгел,
Калган нигез дә юк бабамнан.
Гомернең бар төшен актарсам да,
Аннан якын җирне табалмам.

* * *

Бер елны Сибгат Хәкимне халык утырышчысы итеп сайлыйлар.

— Әйдә, судка йөреп кара, син бик йомшак күңелле кеше, бераз катылана төшәрсең,— ди аңа Язучылар союзының партия оешмасы секретаре.

— Минем әллә ни «катыланырга» теләгем юк иде, чөнки мин кечкенәдән бирле төрле талаш-гаугаларны яратмадым,— ди С. Хәким.

Баштарак ул судка гади тыңлаучы сыйфатында гына йөри, суд кешеләрен узып фикер әйтми. Ләкин болай озак читтә калу мөмкин булмый, билгеле. «Ваемсызлык — шагыйрь эше түгел,— ди С. Хәким.— Кешеләрне яратып та, аларның язмышына битараф карау мөмкин түгел».

Тагын күпмедер вакыт уза, С. Хәким инде судта карала торган мәсьәләләргә актив катнаша башлый. Суд хезмәткәрләре үзләре дә һәрнәрсә турында төптән уйлый торган бу кешенең сүзләренә күбрәк колак сала, аның фикерләре белән исәпләшә башлыйлар.

Судта йөрү, икенче яктан, С. Хәкимнең үзен дә рухи яктан баета, тормышны, кешеләрне тирәнрәк аңларга өйрәтә, алай гына да түгел, аның иҗатына яңа темалар, яңа бизәк һәм образлар өсти. Шул рәвешчә, «Суд залыннан» дигән шигырьләр циклы барлыкка килә.

Әлеге циклда Сибгат Хәким гади кешеләрнең шатлык-кайгыларына якынрак килә, җир йөзендә эшләнгән

һәрнәрсә өчен үзенең намусы каршында «мең тапкыр җаваплы» булуын тагын да тирәнрәк аңлый.

Бигрәк тә шунысы игътибарга лаек, шагыйрьне катлаулы җинаять процесслары кызыктырмый, аның күңелен иң элек кеше хисләре, аларның язмышы, көндәлек тормышы җәлеп итә. С. Хәкимнең куен дәфтәрләрендә судта эшләгәндә теркәгән күп кенә җинаять процесслары турындагы язмалары бар. Ул, аларның берсе буенча повесть язарга уйлап, хәтта тәфсилле генә план да төзеп карый. План төзи, ләкин язмый. Һәм юкка гына түгел. Детектив характердагы вакыйгалар шагыйрьнең табигатенә үк ят. Аны иң гади, тормышчан, күпләр өчен типик вакыйгалар гына үзенә тарта. «Фәрхинур» исемле шигыре бу яктан аеруча характерлы.

Фәрхинур тормышка чыгып ире белән нибары берничә көн генә яшәп кала: арага рәхимсез сугыш килеп керә. Сугыш буена ул, зур түземлелек белән, ирен көтә... Сугыш бетә. Исән кешеләр үз нигезләренә әйләнеп кайта. Аның иренең генә ни үле, ни тере хәбәре юк. Төннәрен шылт иткән тавыш ишетелдеме, бу улдыр, бәлки, ул кайткандыр, дип Фәрхинур йөгереп Идел ярына чыга. Шулай еллар уза...

Шул рәвешчә сагынып-саргаеп көткән иреннән уйламаганда-көтмәгәндә аерылырга ризалык сорап телеграмма килеп төшә. Бу шигырьдә С. Хәкимнең тавышы аеруча көчле нәфрәт белән яңгырый:

Гарьләнә ул, кимсенә ул шуңа:
Кем белән бит монда судлаша.
Бер югалган килеш яши бирсә,
Телеграмма әгәр сукмаса,
Элеккечә калыр иде хисләр,
Хәсрәтеңне эчкә яшереп тә
Асрар идең, йөрер идең горур,
Кер төшерми үткән яшьлеккә...

Фәрхинур өчен иң кыены, газаплысы шул: ул еллар буе кадерләп, саклап килгән мәхәббәт хисләрен йөрәгеннән йолкып ташларга тиеш. Шигырьдә без аның ирен күрмибез. Хәер, нәфрәттән бүтәнгә хакы булмаган бу кешенең кирәге дә шулкадәр генә. Безнең алда иң кирәклесе — Фәрхинур үзе, аның саф, зур мәхәббәте, олы кешелек хисләре.

Суд утырышларының берсендә, кешеләрнең бер дә мәгънәсезгә үз тормышларын үзләре бозуларына по-



шынып утырганда, шагыйрьнең хәтеренә Туры Газзә исемле авылдашы төшә. Тормыш Газзәне кешене кешедән, яхшыны яманнан аерырга өйрәткән. Авылда ул әдәп-әхлак нормалары сагында торучы бер кешегә әйләнгән. Гаиләдә тынычлык урнаштыру, үпкәләшкән яшьләрне килештерү, төрле җилбәзәк-җилкуарларны акылга утырту өчен Газзәнең бер сүзе җиткән:

Кем тормышын көйгә салмады ул,
Ирнең хәтта азып-тузганы
Тәүбә итте Газзә каршысында,
Юк, икенче судка узмады...

Шуның кебек, шагыйрьнең туры сүзе дә кешеләрне яшәргә, тормышка җитдирәк карарга өйрәтә, юлдан тайпылганнарны дөрес юлга чыгара.

«Суд залыннан» циклы С. Хәкимнең иҗади җитлегү, гражданлык хисләре көчәю юлында алга таба бер адымы булды.

* * *

Лиризм хисе тирәнәю белән беррәттән, шагыйрь иҗатының тематикасы да киңәя, шигырьләренең социаль-политик яңгырашы көчәя, гражданлык тойгылары үсә бара.

Утызынчы-кырыгынчы елларда Сибгат Хәким, туган як табигате, мәхәббәт, кешеләрнең эчке кичерешләре турындагы шигырьләр белән беррәттән, социаль-политик эчтәлекле, иҗтимагый әһәмияткә ия булган зур мәсьәләләр күтәргән шигырьләр дә иҗат итә. Әмма ул шигырьләрдә риторикадан котылып бетә алмау, әзер схемалар белән эш итү шактый сизелә әле. Юк, алар «дежур» шигырьләр, ул елларда вакытлы матбугатта чагылган рифмаланган газета мәкаләләре түгел. Ләкин ул шигырьләр әле шагыйрьнең пейзаж һәм интим лирика өлкәсендәге әйбәт әсәрләреннән күп кайтыш. Иҗтимагый мәсьәләләр турында язарга кирәклеген шагыйрь акылы белән тойса да, язарга алынган вакыйгакүренешләрне йөрәге аша үткәреп җиткерә алмый.

Моңарчы бер-берсенә параллель рәвештә килгән бу ике агым — «иҗтимагый як» белән «шәхси як» илленче елларның икенче яртыларында бергә кушыла. Сибгат Хәким үз иҗатында сыйфат ягыннан алга таба зур сикереш ясый. Бу сикереш исә аның үз иҗат биогра-

фиясе белән генә түгел, беренче чиратта, тормышта туган иҗтимагый үзгәрешләр белән аңлатыла. Иҗтимагый тормыштагы үзгәрешләрне шагыйрь үз кичерешләре, шәхси тормышына кагылышлы үзгәрешләр итеп кабул итә. Һәм, татар совет поэзиясендә беренчеләрдән булып, ул партиянең егерменче съездыннан соң урнашкан иҗтимагый атмосфераны чагылдыра. Ватан язмышы аның үз язмышы белән бергә үрелә. Гомуми пафостан һәм коры сүзләрдән ваз кичеп, шагыйрь үз иҗатындагы иң матур сыйфатларны — эчкерсезлекне, сурәтләү-тел чараларының табигыйлеген, тәэсир көчен саклап кала, аларны тагын да үстерә һәм көчәйтә төшә. Сибгат Хәким иҗатындагы әлеге ике сыйфат — лиризм һәм иҗтимагый пафосның бергә кушылуы механик төстә бармый. Аның поэзиясенең иҗтимагый яңгырашын һәм идея-эстетик әһәмиятен тагын да көчәйткән өр-яңа сыйфат туа.

Ул катлаулы образлар белән эш итәргә тырышмый, «хәзерге заман стиле» дип йөртелгән ясалма нәрсәләрдән ерак тора. Аның төп үзенчәлеге — үз-үзе булып калуында, уй һәм кичерешләренең табигыйлегендә. Ул бары тик үзен тирәнтен дулкынландырган, асылына ахырынача төшенгән, җанын өзлексез тынгысызлап торган нәрсәләр турында гына яза.

Сибгат Хәким иҗатында лирика һәм публицистиканың бербөтен булып әверелүенә мисал итеп аның «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән шигырен китерергә мөмкин. Беренче карашка шигырь табигать күренешләрен сурәтләгән гадәти юллардан башланып китә кебек:

Казан әле, Казан уянмаган,
Яфрак белән яфрак серләшә.
Йөрим таңда Ленин урамында,
Күңелем Ленин белән сөйләшә...

Җәйге матур таңга сокланудан туган салмак хис акрынлап катлаулырак икенче бер хис белән алышына. Без шагыйрьнең тавышы көчәйгәннән-көчәя, фикере үткенләнгәннән-үткенләнә, киеренкеләнгәннән-киеренкеләнә баруын тоябыз. Тора-бара шагыйрьнең поэтик мохитында бөтен ил, бөтен планета урын ала.

Без узарга тиеш, әй, юллар бар,
Зур эшләргә чакырып ил дәшә.
Юлга шулай чыгар алларыннан
Күңелем Ленин белән сөйләшә.



* * *

«Шигырь ничек туа? Бу сорауга җавап бирер алдыннан мин шигырь төзелеше законнары, поэтик осталык мәсьәләләре турында түгел, ә, беренче чиратта, поэзиянең төп чыганагы — тормыш турында уйланам. Кайсы гына шигыремне искә төшерсәм дә, аның нигезендә берәр реаль вакыйга яки факт ята. Шигырьләрне тормыш тудыра»,— дип яза С. Хәким.

Югарыда күреп үткәнебезчә, С. Хәким иҗатына балачак тәэсирләре дә, халык утырышчысы булып эшләү һәм фронт тәҗрибәсе дә үз эзен салган. Тик бу — механик процесс түгел. Бер көндә күргәннәрнең бөтенесен рәттән рифмага салып чыгу өчен генә дә шагыйрьгә күпме шигъри юл кирәк булыр иде! Язучы, котылгысыз рәвештә, сайларга, тормыш фактлары һәм вакыйгалары арасыннан иң әһәмиятле, иң характерлыларын гына алырга мәҗбүр. Шул сайлау процессында аның индивидуаль иҗат йөзе, идеаллары, дөньяга карашы чагыла.

Бервакыт автор миңа «Тәрәзә рамнары» исемле шигыренең язылу тарихын сөйләгән иде:

«Образның прототибын — авылдашым Гыйльметдинне мин кимендә утыз ел беләмдер. Кызыклы вакыйгаларга бай тормышын беләм, гаиләсен, хатынын, балаларын, аның бөтен гадәтләрен, сәер якларын, сөйләү үзенчәлеген беләм.

Мондый бай материал белән прозаик язучы, ихтимал, повесть яки роман яза алган булыр иде. Әмма мин шагыйрь. Һәм мин, Гыйльметдингә кайсы яктан якын килергә белмичә, әллә никадәр азапланып йөрдем. Төгәлрәк итеп әйткәндә, бу акыллы, гади кешенең асылын ачарлык шигъри образ таба алмый йөдәдем».

Ниһаять, Гыйльметдиннең бик җентекләп, җиренә җиткереп тәрәзә рамнары ясавын күзәтеп утырганда, шагыйрь башына бәхетле уй килә. Гыйльметдиннең җир йөзендәге иң шигъри һөнәр ияләренең берсе икәнен аңлый ул. Тәрәзә рамнары аша кешеләргә яктылык керә, кояш нуры керә. Тирә-як авыллардагы бик күп өйләрнең тәрәзәләрендә Гыйльметдин ясаган рамнар тора... Шулай итеп, шигырьнең үзәк образы табыла:

Гыйльметдин ясый ул
Тәрәзә рамнары,

Керə дə утыра
Авылның таңнары...

Томалый кайвакыт
Күңелсез бураннар...
Язларны алдан ук
Сизəлəр бу рамнар.

Лəкин Гыйльметдиннең һөнəрен иң шигъри һөнəр дип əйтү генə шигырь язу өчен аз əле. С. Хəким күп тапкырлар Гыйльметдин белəн иркенлəп сөйлəшеп утыра, аның нилəр уйлавын, аңа нəрсə кирəген, аның иң изге телəге — тынычлык икəнен яхшы белə. Аның һөнəреннəн табигый рəвештə килеп чыга торган бу фикер баштагы поэтик образны көчəйтеп, үстереп җибəрə, аның белəн керешеп китə.

Елмайсын иде бер
Бар дөнья, аннары
Ник шунда шатлыктан
Шартламый рамнары...

* * *

1958 елда, язгы матур көннəрнең берсендə, «Совет əдəбияты» журналы редакциясендə телефон шалтырый:

— Ишеткəнегез бармы икəн? — дип сорый дулкынланган тавышлы бер кеше.— Арча районының Ислетар авылында Сəлах Хисамиев дигəн бер кеше яши, ул Ленин янында булган...

Бу хəбəр белəн шагыйрь С. Хəким дə кызыксына. Ул Күлле-Киме күршесендə генə урнашкан Ислетар авылына китə һəм С. Хисамиев белəн кат-кат очрашып озаклап сөйлəшеп утыра.

Беренче очрашуда ук Сəлах абзый шагыйрь күңелендə əйбəт тəэсир калдыра. Аз сүзле, тыйнак бер кеше була ул. Һəр очраган кеше алдында үзенең күргəннəре белəн мактанып йөрми, аның Ленин янына керүен дə хəтта очраклы рəвештə генə белəлəр. Бу кеше белəн күбрəк аралашкан саен, С. Хəким бер нəрсəгə ышана бара: Хисамиев Сəлах бары дөресен, булганны гына сөйли. Ул сөйлəгəннəрне, кайберəүлəр уйлаганча, бары əкият дип кенə исəплəсəң дə, халыкның телəк-омтылышларын чагылдырган гүзəл əкият, телəсə нинди шигъри əсəрнең нигезенə салынырлык менə дигəн легенда була бу. Шулай итеп, «Ленин фəрманы белəн» дигəн поэма язу уе туа.



Поэманың төп герое — көчле революция дулкыннары белəн уянып, тормышта үз урынын, үз ролен аңлау дəрəҗəсенə күтəрелгəн гади крестьян егете Хисам. Хисамның Ленин янына керүен тасвирлаган урыннар аеруча уңышлы язылган. Юк, Ленин янына ул үз исеменнəн генə килмəгəн, аның артында — бөтен татар халкы, бөтен Татарстан.

Шагыйрь вакыйгаларның кысаларын киңəйтеп җибəрə, сурəтлəнгəн хəллəрнең тарихи əһəмияткə ия булуын басым ясап күрсəтə. Ленин һəм Татарстан, Ленин һəм татар халкы — поэманың төп темасы əнə шул. Крестьян улы Хисам язмышы аша шагыйрь татар халкының юлбашчыбыз Ленинга булган кайнар мəхəббəтен сурəтли. Шуның белəн Казан һəм Татарстанның Ленин күңеленə аеруча якын, үз булуын ача. Хисам үзенең хəле турында сөйли, юлбашчының күз алдында ерак балачак күренешлəре җанлана:

Җилкеткəн аны,
Җилкеткəн Казан...
Əй, язны көткəн
Шул карлы юллар...
Ул йөргəн, күргəн
Шул карлы юллар...

Лəкин Ленин белəн Хисамны, үткəнгə караганда, Татарстанның килəчəге күбрəк борчый, аларны яңа туфраклы, Тукайлы якта шатлык җырларының хəзерге көндə ничек яңгыравы кызыксындыра. Үзенең бөтен агышы белəн поэма укучыны түбəндəге сүзлəргə əзерли:

Татарстанны,
Хисамиларны
Бөек Лениннан
Аермый еллар.
Хисамиларга
Барырга кирəк
Тагын йөз еллар
Шушы чор аша...
Коткарды Ленин
Диярлəр алар,
Əгəр берəрсе
Юлда сораса...

Автор поэманы тирəн дулкынлану, зур күтəренкелек белəн яза. Беренче тапкыр поэма шагыйрьнең 1959 елда чыккан җыентыгында басыла.